**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительного комитета Азнакаевского муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**«01» октябрь 2020 ел** **№ 258**

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 23 ноябрендәге 286 нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (03.06.2013 ел, №135, 31.12.2013 ел, №331, 02.03.2015 ел, №340, 18.11.2016 ел, №337, 11.10.2017 ел, №253, 10.11.2017 ел, №289, 2018 ел, 28 ноябрь, №311, 10.04.202020 ел, №119 карарлары редакциясендә)

2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль закон таләпләре нигезендә, карар бирә:

1. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 23 ноябрендәге 286 нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру турындагы нигезләмәгә (31.12.2013 ел, №331, 02.03.2015 ел, №340, 18.11.2016 ел, №337, 11.10.2017 ел, №253, 10.11.2017 ел, №289, 2018 ел, 28 ноябрь, №311, 10.04.202020 ел, №119 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 6 бүлек исемен "Ташламалы туклануны оештыру тәртибе (гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чарасы)" яңа редакциядә бәян итәргә.

1.2. барлык текст буенча"Ташламалы туклану" сүзләреннән соң, "(укучыларга өстәмә социаль ярдәм чарасы)" сүзләрен тиешле килешләрдә өстәргә.

1.3. түбәндәге редакциядә яңа 6.8 пункт өстәргә:

«6.8. Агымдагы финанс елында бюджет йөкләмәләре лимитлары җитмәгән һәм (яисә) булмаганда, җирле үзидарә органының башка норматив хокукый акты нигезендә субсидия бирелә.

Чираттагы финанс елында җирле үзидарә органының норматив-хокукый актында билгеләнгән субсидия алучыга субсидияләр бирү, бюджет йөкләмәләре лимитлары

җитмәүгә һәм (яисә) булмау сәбәпле, аны бирү мөмкин булмаган очракта, күрсәтелгән категорияләргә һәм (яисә) сайлап алу критерийларына кабат тикшерү узмыйча бирелә.».

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет - телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары
Д. Р. Гыйләҗевка йөкләргә.

Җитәкче А. Х. Шәмсетдинов